ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 31 » октябрь 2019 ел** **№ 832**

**2020 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2020 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Арча муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне матди карап тотуга норматив чыгымнарны;

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә «2020 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2019 елның 02 октябрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яки Арча муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.И. Гарифҗановка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

**Арча муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга чыгымнар**

| тибы һәм төре гомуми белем бирү оешмасы | Территория ягыннан урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә, елына норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 90980 |
| | авыл җирлеге | 92342 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 137238 |
| | авыл җирлеге | 141713 |